| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА БУРМЕТЬЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КИЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Киекле ав. **КАРАР**

«09» март 2022 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Үрнәк авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылында 2022 елның 20 мартына 11 сәгать 00 минутта Үрнәк авылы, Нагорная урамы, 1нче йорт адресы буенча яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча түбәндәге элегрәк расланган карарга үзгәрешләр кертү буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Үрнәк авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2021елның 20 ноябрендәге 1нче номерлы карар;

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Үрнәк авылы торак пунктында узган гражданнар җыенының 2021елның 20 ноябрендәге 2нче номерлы карары.

2. Үрнәк авылында яшәүче гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла дип билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында элегрәк расланган 20.11.2021 ел, №1 һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылы торак пункты

гражданнары җыенының 20.11.2021 ел, №2 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

Киекле авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм теркәлгән, 1 гр инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 1000 сум күләмендә кертелгән үзара салымны югарыда күрсәтелгән карарлар белән расланган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелүче эшләр исемлеген түбәндәге эш төрләре белән тулыландырырга:

- Үрнәк авылы зиратын төзекләндерү һәм сезонлы карап тоту өчен товарлар (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр) сатып алу (коймаларны ремонтлау, агачларны кисү, үләнне чаптыру, койманы буяу, керү юлларына вак таш җәйдерү).

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Үрнәк авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге башлыгы Л.И.Кашапова